Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

РЕШЕНИЕ
10.01.2023 ел

КАРАР
№123

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының» Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 04.06.2018 ел, № 92 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тышкы эшләр министрлыгы 17.09.2022 ел, №1015 «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «28.03.2018 ел, №182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары буенча, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт хакы түләү нигезләмәсен раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына 04.06.2018 ел №92 (Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 10.07.2018 ел, №98, 26.10.2018 ел № 109, 05.02.2021 ел, № 28, 03.10.2022 ел, № 100 карарлар кабул иткән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 3 нче пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт хакы түләү чыгымнары күләме елына 13,27 айлык акчалата бүләк тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Штат расписаниесен расларга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән бирле үз көченә керә һәм 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны җирлек территориясендә урнашкан махсус билгеләнгән стендларда халыкка җиткерергә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советының Бюджет һәм икътисадый мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе

Р.Ә.Кәримов